МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 51/о

ПРИКАЗ БОЕРЫК

"24" 03 2020

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәрләре) өчен күпфатирлы һәм торак йортларда салкын, кайнар су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу буенча коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативларын раслау турында» 2012 елның 21 августындагы 131/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәрләре) өчен күпфатирлы һәм торак йортларда салкын, кайнар су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу буенча коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативларына үзгәреш кертү хакында

боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәрләре) өчен күпфатирлы һәм торак йортларда салкын, кайнар су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу буенча коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативларын раслау турында» 2012 елның 21 августындагы 131/о номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2013 елның 20 маендагы 62/о номерлы, 2017 елның 5 маендагы 95/о номерлы, 2019 елның 10 сентябрендәге 119/о номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәрләре) өчен күпфатирлы һәм торак йортларда салкын, кайнар су белән тәэмин итү һәм ташландык

суларны агызу буенча коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативларына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

түбәндәге юлны

| | |
|---|---|
| «Җир кишәрлегенә су сибү (май аеннан башлап сентябрь аена кадәр) | 0.043» |

киләсе редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Җир кишәрлегенә су сибү (май аеннан башлап август аена кадәр) | 0.064». |

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С.Миңнехановага әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

Министр Ф.М. Хәнифов